СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2023 г.Лениногорск № 82

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 55 номерлы карары белән расланган муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының хәвеф-хәтәр индикаторлары турында 12.10.2023 01-54/7098 номерлы хатын карап, Татарстан Республикасын «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 55 номерлы карары белән расланган муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеген яңа кушымтада бирелгән редакциядә бәян итәргә.

2.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының экология, табигатьтән файдалану, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Лениногорск муниципаль
районы башлыгы,
Совет рәисе

Р.Г.Хөсәенов

«Лениногорск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге Советының
2023 елның 23 ноябрендәге 82 номерлы
карарына кушымта

## Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча чишелешләр булган муниципаль торак фондының торак урыннары булган күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышының өч ай рәттән ике һәм аннан да күбрәк беркетмәләре муниципаль торак контроле органына керү.

2. Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне контрольдә тотучы затлар тарафыннан бозу фактлары турында гражданнардан( мөрәҗәгать итүченең шәхесен ачыклау мөмкин булган ысул белән мөрәҗәгать иткән очракта)яки күпфатирлы йортта урын милекчеләре булган оешмалардан, күпфатирлы йорттагы урыннан файдаланучылардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, дәүләт мәгълүмат системаларыннан Дәүләт торак күзәтчелеге органына, муниципаль торак контроле органы адресына кергән алдагы календарь елның аналогик шул чоры белән чагыштырганда вакыт берәмлеге (ай, квартал) эчендә мөрәҗәгатьләр санының өч тапкыр һәм аннан да күбрәк артуы.

3. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Торак кодексының 165 статьясындагы 5 өлеше нигезендә билгеләнгән урнаштыру тәртибе, рәвешләре, сроклары һәм вакыты нигезендә урнаштырылырга тиешле мәгълүматны өч һәм аннан артык ай дәвамында актуальләштерүнең булмавы.

4. Контрольдә тотылучы зат идарәсендә булган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтнең төзексезлеген бетерү эшләрен башкару өчен ремонт бригадаларын Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматы буенча атнага биш мәртәбәдән күбрәк чакыру очраклары.

5.Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләрнең ачыклануы.